**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396) 2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

13 апрель 2021 ел № 10

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 25 сентябрендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Чирмешән районы прокурорының 2021 елның 24 мартындагы 261р номерлы муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында карарына протестын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ:**

1. Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 25 сентябрендәге «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 15 номерлы карары белән расланган Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 25 сентябрендәге 15 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына 1 нче кушымтада

- 2 бүлектә. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты 2.5 п. яңа редакциядә бәян итәргә:

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы | Белешмә (өземтә) бирү | Авыл җирлеге уставы, РФ ГК, РФ Җир кодексы, РФ ТК, Нотариат турында законнар нигезләре, 122-ФЗ, 74-ФЗ, 210-ФЗ, Росрегистрация боерыгы |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органы исеме | Башкарма комитет | Авыл җирлеге уставы |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Белешмә (өземтә).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән телдән яки язмача баш тарту | Авыл җирлеге уставы, РФ ГК, РФ Җир кодексы, РФ ТК, Нотариат турында законнар нигезләре, 122-ФЗ, 74-ФЗ, 210-ФЗ, Росрегистрация боерыгы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнары белән туктатып тору мөмкинлеге каралган | Гаризаны теркәгәннән соң өч көннән[1] дә артмый.<br>Мөрәҗәгать иткән көнне муниципаль хезмәт күрсәтүдән телдән баш тарту.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | |

[1] Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы суммар сроктан чыгып, административ процедураларны башкару өчен кирәкле минималь сроктан чыгып билгеләнде. Административ процедураларның озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Хезмәт күрсәтү турында гариза (телдән яки язмача).<br>Документлар (оригиналлар) (2 нче кушымта).<br>Язма рәвештә гариза бер нөсхәдә тапшырыла.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат);<br>почта аша җибәреп.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тәкъдим ителергә (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документларны тапшыру таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе;<br>карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Тиешле булмаган зат тарафыннан документларны тапшыру;<br>2) Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген төгәл аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар бар;<br>4) Тиешсез органга документларны тапшыру | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, йә гаризада һәм (яки) | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтү биналарына, көтү залына һәм гариза бирүчеләрне кабул итү урынына таләпләр, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларның файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм ясауга карата таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән һәм инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләренә киртәләрсез үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле тиешле урнаштырылган җиһаз һәм мәгълүмат йөртүчеләр белән җиһазландырылган биналарында һәм бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла;<br>инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматларының, шулай ук язуларның, билгеләрнең һәм башка текст һәм график мәгълүматларның Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләре белән кабатлануы, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурд тәрҗемәче ярдәменнән файдалану тәэмин ителә;<br>инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз үтеп керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү һәм алар чикләрендә күчү), мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып, күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең тотрыклы тайпылышларына ия булган инвалидларны озату һәм аларга ярдәм күрсәтү;<br>озатып йөрүче этне кертү тәэмин ителә, әгәр аны махсус укытуны раслаучы документ булса;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла;<br>халыкка хезмәт күрсәтүче белгечләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт | Кагыйдәләр, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (2020 елның 8 декабрендәге редакциясендә) |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашуы;<br>белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү башкарыла торган бүлмәләр кирәкле санда булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында www.cheremshan.tatarstan.ru, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү өчен чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату (запрос) биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактан торып эш урыннары аша муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә, консультаци, документларны кабул итү һәм бирү эшен КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан сайтта, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, КФҮ алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге федераль мәгълүмат адреслы системасы порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталын (http:// www.gosuslugi.ru/) файдаланып бирелә. | |

- 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар яисә аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү»;

- 5 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә: «Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соратуны, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15_1 статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тәкъдим итү яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда бирү каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче авыл җирлеге Башкарма комитетының, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм опечаткаларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу

8) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срокларын яки тәртибен бозу;

9) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны яисә белешмәләрне мөрәҗәгать итүчедән дәүләт яки муниципаль

хезмәт күрсәтү өчен яисә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә таләп итү, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

1. Шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы булып торучы тиешле җирле үзидарә органына (алга таба - күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр югары органга (булганда) бирелә яисә ул булмаганда, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла. Күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күп функцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итүендә кабул ителергә мөмкин.

3. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган төзелеш өлкәсендәге процедураларның тулы исемлегенә кертелгән шәһәр төзелеше мөнәсәбәтләре, процедуралар субъектлары булып торучы юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның,

муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның вазыйфаи затларының, яисә муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять мондый затлар тарафыннан әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә йә Россия Федерациясенең монополиягә каршы законнарында билгеләнгән тәртиптә монополиягә каршы органга тапшырыла ала.

4. Җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар белән тиешенчә билгеләнә.

5. Шикаять түбәндәге мәгълүматны тупларга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар, йә мөрәҗәгать итүченең - юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы документлар (булганда), йә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

6. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күп функцияле үзәккә, күп функцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (булганда) кергән шикаять, аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күп функцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән йә җибәрелгән хаталарны һәм опечаткаларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылуга карата шикаять белдерелгән очракта - теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә.

7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән, кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм опечаткаларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

8. Мөрәҗәгать итүчегә әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

8_1. Шикаятьне җавапта канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында 8 пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешма тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба башкарырга кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

8_2. Шикаятьне җавапта канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында, 8 пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составының билгеләре билгеләнгән очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

- Әлеге административ регламентка 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
башкарма комитетына

(җирле үзидарә органы исеме
______________________________
______________________________
(алга таба - мөрәҗәгать итүче).
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары,
яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

Белешмә (өземтә)
бирү турында гариза

Белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм_________________________.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:
Яшәү урыныннан белешмә, йорт кенәгәсеннән өземтә, элеккеге яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

1. Шәхесне раслаучы документлар.

2. Йорт китабы.

Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

1. Шәхесне раслаучы документлар.

2. Йорт китабы.

3. Чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

3.1. Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар.

Үлүченең яшәү урыныннан белешмә алу өчен үлем көненә:

1. Шәхесне раслаучы документлар.

2. Йорт китабы.

3. Үлем турында таныклык оригинал.

4. Чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе

4.1. Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;

Сорату буенча сканерланган документларның оригиналларын тапшырырга әзермен.

(дата)

(имза)

(ФИА)

Әлеге административ регламентка 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2 нче кушымта

Яшәү урыныннан белешмә, йорт кенәгәсеннән өземтә, элеккеге яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

1. Шәхесне раслаучы документлар.

2. Йорт китабы.

Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

1. Шәхесне раслаучы документлар.

2. Йорт китабы.

3. Чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

3.1. Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар.

Үлүченең яшәү урыныннан белешмә алу өчен үлем көненә:

1. Шәхесне раслаучы документлар.

2. Йорт китабы.

3. Үлем турында таныклык оригинал.

4. Чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе

4.1. Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;

2. Үз көчен югалткан дип танырга:
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 25 сентябрендәге 15 номерлы карары
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чирмешән авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.С.Ганиева